# Апаз балалар бакчасының үткәне...бүгенгесе...

Мәктәпкәчә тәрбия буенча 1 нче сьезда мәктәпкәчә яшьтәге балаларга төрле яклап туган телдә тәрбия һәм белем бирү бурычы куела. 1918 нче елның декабрендә Казанда балалар бакчалары ачыла. Шуннан соң районнарда бер-бер артлы балалар бакчалары ачыла башлый. 1918 елда Казан шәһәрендә барлыгы 27, ә Казан өязе буенча 48 балалар бакчалары ачыла башлый. Апаз балалар бакчасының 1930 нчы елларга кадәр үк ачылганы билгеле. Бөек Ватан сугышы елларында, Апаз авылы балалары белән бергә Эстониядән эвакуацияләнгән балалар да тәрбияләнә. Ул вакытта мөдир булып Рәхилә исемле читтән килгән апа эшли. Ул вакытта апаз авылы Кенәр районына караган була. Рәхилә апа үзе җәяүләп Кенәр авылыннан чана тартып балаларга ризык ташый. Тәрбиячеләр белән бергәләп мичкә ягырга утын ташыйлар, ә балалар өйләреннән йомырка, май, сөт ризыклары алып килә торган булганнар. 1950 нче еллар тирәсендә балалар бакчасы бинасы чиркәү бинасы урынына күчә. 1950 нче елларда мөдир булып Рәшидә исем ле хатын-кыз, тәрбияче булып Ибрагимова Саймә, пешекче булып Ахметова Маһирә апалар эшлиләр. 1963 нчееларда Чистайда укып кайткан Батырова Исламия исемле хатын-кыз эшли башлый. 1965 нче елларда балалар бакчасына мөдир булып Закирова Лира Садыйк кызы килә. Ул вакытта бакчада 28 бала тәрбияләнә. 1965 нче елда тәрбияләнүче балаларның тәрбиячесе Мухаметзянова Алфинур апа була. 1972 нче елдан башлап совхоз директоры Кәримов Вагыйз җитәкчелегендәге иске балалар бакчасы бинасына яңа бина өстәлә. Балалар ике туркемгә җыйнала. 1972 нче елдан башлап тәрбияче булып Миннебаева Саҗидә,пешекче булып Закирова сәрия, тәрбияче ярдәмчесе булып Ибрагимова Асия, Гарифуллина Сәвия, Самигуллина Дания, Һадия апалар эшлиләр. 1987 нче елдан мөдирлекне Садикова тәслимә Исрафил кызы ала. Ул елларны тәрбиячеләр булып Хазиева кадерия, Мазитова Фәндәлия, Хамматова Фларида, тәрбияче ярдәмчеләре булып Насибуллина Сурия, Самигуллина Дания, пешекче булып Гафетдинова Гадилә апалар эшлиләр Еллар үткән саен балалар бакчасына таләпләр дә үзгәрә һәм Апаз авылына яңа балалар бакчасы төзүне 90 нчы еллардан соң планга кертәләр. Бу план 1997 нче ел ахырына тормышка ашырыла һәм кулланышка тапшырыла. 1998 нче елның 11 нче февраленнән бу бина ике төркемгә бүлеп, балалар кабул итә башлый. Урын 40 балага исәпләнгән. Ачылганда бакчага "Кояшкай" исеме бирелгән була. Шушы елдан бакчаны Ахметова Роза Рәхимҗан кызы җитәкли башлый. Ул елларны тәрбиячеләр булып Садикова Тәслимә, Хазиева Кадерия, Мазитова Фәндәлия, тәрбияче ярдәмчеләре Насибуллина Сүрия, Галимова Нурфия, пешекче булып Гафетдинова гадилә, кер юучы булып Минибаева Рәмзия апалар эшләгәннәр. 2017 нче елны безнең балалар бакчасы ныклап төзекләндерү программасына кертелгән. 2010 нчы елдан 2021 нче елга кадәр бакча мөдире Сибагатуллина Фирая Гафур кызы хезмәт куя. Тәрбиячеләр Мазитова Фәндәлия, Садикова Тәслимә, Миннебаева Гөлшатлар, тәрбияче ярдәмчеләре Насибуллина Сүрия, Хайретдинова Ләйсәннәр, пешекче булып Файзрахманова Рәйсә, кер юучы булып Минибаева Рәмзия апа, ремонт эшләрен башкаручы Самигуллин Рафил абыйлар эшлиләр. 2021 нче елдан бүгенгесе көнгә кадәр бакча мөдире Зәйнуллина Индира Тәлгать кызы эшли. Тәрбияче Нигметзянова Лилия Гаптелахатовна, Тәрбияче ярдәмчесе Насибуллина Сурия, пешекче Фахрутдинова Ралия Ханифовна, пешекче ярдәмчесе Хайрутдинова Лейсан Хайдаровна, кер юучы Фәйзиева Зәлидә Камиловна, ремонт эшләрен башкаручы Самигуллин Рафильләр хезмәт куя.

Балалар бакчасының материаль техник базасын баетуга бөтен көчне куеп эшлибез. Бакчада белем һәм тәрбия бирү өчен кирәк булган барлык шартлар булдыруны максат итеп куйдык һәм тормышка ашыру өстендә хезмәт куябыз.

Яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып төзелгән "Федераль белем бирү программасы" белән эшлибез, бүгенгә көндә 19 бала балалар бакчасына йөри. Көндәлек режим, расписаниеләр челтәре, балалар исемлеге, хезмәткәрләрен эш графиклары төзелгән, расланган. 2025 нче елның 1 нче сентябереннән 5 балабыз беренче тапкыр мәктәп бусагасын атлап керәчәк.

Бакчабызда белем һәм тәрбия бирү буенча кирәкле булган барлык шартлар да бар. Балаларның уйлау сәләтен үстерү өчен өстәл уеннары, уен почмаклары яңартылып-җиһазландырып торыла, төрле дидактик һәм сюжетлы уеннар өчен кирәкле булган җиһазлар булдырылып яңартылып тора. Аерым бүлмәдә татар халык музее оештырылган, яңа экспонатлар белән яңартылып торыла.

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга милли-мәдәни тәрбия бирү максатыннан, безнең балалар бакчасы үзебезнең чиктәш күрше республика (татар, рус, мари, керәшен) милләтләренең мәдәниятын, гореф- гадәтләрен, тарихын өйрәтүне максат итеп куйдык. Без янәшәбездә яшәүче башка милләт халыкларын хөрмәт итәргә, балаларда милләтара дуслык хисләрен тәрбияләргә тиешбез.

# Ата-аналар өчен киңәшләр...

Гаилә – бала өчен иң беренче социаль дөнья. Яшь буын хезмәткә иң элек шунда өйрәнә. Кече яшьтән үк хезмәткә өйрәтү аның табигатенә бик туры килә. Балага хас булган активлык, барын да белергә, үзе эшләп карарга омтылу хезмәттә аеруча ачык чагыла. Кечкенә бала уен аша хезмәткә тартыла. Ул әнисе яисә әтисе эшләгәнне карап торырга ярата, аннары шуны кабатлый: шофер, сатучы яки врач булып уйный. Уйнаганда исә төрле әйберләр белән эш итә, хәрәкәтләнә. Әгәр 2-3 яшьлек улыгызга яки кызыгызга өстәл сөртергә кушсагыз, ул әлеге хәрәкәтне шактый озак кабатлар. Чөнки бу эш балага зур шатлык һәм куаныч китерә, әмма бу хәрәкәтләрне ул механик рәвештә генә башкара. Ә 5-6 яшьләрдә инде аңарда үзенә тапшырылган эшне пөхтәрәк, әйбәтрәк итеп башкару омтылышы көчәя. Әтисе яисә әнисе башкарган эшне дә аңлы рәвештә кабатлый башлый. Биредә ата-ана балага ярдәм итәргә, аның эшчәнлегенә тиешле юнәлеш бирергә тиеш. Югыйсә аның хезмәт эшчәнлегә сабый баланыкы кебек бик гади һәм эчтәлексез булып калуы бар. Белгәнебезчә, хезмәт баланың физик һәм психик үсешенә уңай тәэсир итә, аның мускулларын ныгыта, игътибары, күзәтүчәнлеге, тапкырлыгы артуга ярдәм итә. Теләк булганда, бала башлаган эшен яхшырак итеп очлап чыгарга омтыла. Ә бу, үз чиратында, ихтыяр көчен тәрбияли, һәртөрле каршылыкларны җиңәргә, куелган максатка ирешергә өйрәтә. Практик күнекмәләр баланың хәтеренә нык сеңеп кала, аның фикерләү сәләте арта, ул торган саен күбрәк белергә омтыла. Хезмәт баланы рухи һәм физик яктан да чыныктыра. Бала да үзе эшләгән әйбергә, өлкәннәр дә шундый ук саклык, игътибар белән карарга тиеш. Чөнки үз хезмәте аша бала олылар хезмәтен дә ихтирам итәргә өйрәнә. Ул тирә-ягындагы кешеләрнең өйдә, заводта, кырда яки бакчада ничек эшләвен хәтеренә сеңдереп бара.
Баланы эшкә өйрәтү өчен, аңа уңай шартлар да тудырырга кирәк. Мәсәлән, кар көрәгәндә, көрәк сабы аның буена туры килергә тиеш, югыйсә ул бик тиз арып, башлаган эшен ахырына җиткерә һәм бернинди канәгатьләнү хисе алмас. Өстәл янында берәр нәрсә ясаганда, баланың дөрес утыруын, аның артык киеренке эшләмәвен, яктылыкның җитәрлек булуын күзәтеп торыгыз. Өлкәннәргә булышам дип, улыгыз яки кызыгыз көче җитмәслек әйберләр күтәрмәсен. Баланың күңеле сүрелмәсен һәм үз көченә ышанычы кимемәсен өчен, кайвакыт аңарга бераз гына булышып җибәрү дә кирәк. Моннан соң ул тагын да канатланып китә. Кыскасы, баланы кечкенәдән үк хезмәткә күнектерү аңарда түземлелек, тырышлык кебек сыйфатлар тәрбияләргә ярдәм итә.



# Бәйрәм белән кадерле әниләребез

Бәйрәм белән кадерле әниләр!
Ноябрь аеның соңгы якшәмбесендә,
24нче ноябрьдә Әниләр көнен
бәйрәм итәбез. Бүген дөньядагы барлык әниләргә иң зур
бүләк — тормыш бүләк итүләре өчен
рәхмәт әйтәсебез килә.Кадерле әниләребез, сезне
Әниләр көне белән котлыйбыз һәм рухи көч,
тормыш зирәклеге,
фәрештә сабырлыгы, хатын-кыз бәхете,
үзара мәхәббәт, өйләрегез
нурлы булуын телибез. Рәхмәт сезгә җылылык, наз һәм
кайгыртучанлык өчен.
Сезгә, кадерлеләребез, һәрвакыт һәм һәркайда
үзегезне кирәкле һәм сөекле кеше итеп
хис итүегезне телибез.

Кем дөньяга кеше бүләк итә,
Ә кешегә якты дөньяны?
Тойгылары кояш кебек кайнар,
Эретерлек гранит кыяны?
Кем күңеле тулган айдай серле,
Язлар сыман назлы, ягымлы?
Шатлыкларын башкаларга бүлеп,
Кайгыларга түзем, сабырлы?
Кем елмая җөйге таң аткандай,
Балкып китә шундук тирә-як?
Нәфислеге гөлләр сокланырлык,
Көләчлектә аңа тиңнәр юк?
Кем куллары өйне, җирне ямьли,
Изгелеге үлчәү тапкысыз?
Ул, әлбәттә, яшәү чыганагы,
Тормыш яме — Әнкәй, хатын-кыз!

















# ЧИШМӘ БАШЫ

1 нче сан

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы АПАЗ БАЛАЛАР БАКЧАСЫ муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесы. Бакчабызның бүгенгесен яктыртучы электрон газета.



## ГАЗЕТАНЫҢ СӘХИФӘЛӘРЕ:

- Апаз балалар бакчасының үткәне...бүгенгесе...
- Бәйрәм белән кадерле әниләр!
- Әти-әниләр өчен киңәшләр...

Баш мөхәррир:бакча мөдире Зайнуллина Индира Тәлгать кызы
Мөхәррир урынбасары:тәрбияче Нигъмәтҗанова Лилия Гаптелхәт кызы